ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨРӘЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның,16 нче сентябре Мөрәле авылы № 9

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегендә жирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР** кабул итте:

1. Мөрәле авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

“Сез, 2020 елда Мөрәле авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән һәм үзара салымнан кергән керемнең түбәндәге юнәлешләрдә тотылуы белән килешәсезме:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- Зур Колаңгы бистәсендә чишмәне төзекләндерү;

*б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;
- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати– телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://muralin-kaybici.tatarstan.ru/.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советына юлларга.

4. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Мөрәле авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Р.Зиннатуллин**